Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

2022 елның 11 ноябре № 6

«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 адресы буенча урнашкан Вахит авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 25 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 адресы буенча урнашкан Вахит авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2022 елның 25 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Клуб урамы, 12 адресы буенча урнашкан Вахит авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Янил авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Коралльы Көчләренә срокльы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Коралльы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 900 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Вахит авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета, экспертиза документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

2) Вахит авылында Беренче Май, Елга урамнарына вак таш җәю (ком һәм вак таш сатып алу, ташу, салу), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү;

3) Вахит авылында урам юл челтәрен карап тоту, юл билгеләрен сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

4) Вахит авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм килешү буенча түләү;

5) чишмәләр территориясен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, чишмә юлларына вак таш җәю, насос сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

6) Вахит авылы зиратлары территорияләрен төзекләндерү һәм карап тоту, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

7) парк территориясен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документларын төзү, килешү буенча түләү;

8) канализация челтәрләрен ремонтлау (торба сатып алу һәм урнаштыру, экскаватор белән канау казу, горизонталь бораулау, коелар өчен тимер-бетон эшләнмәдән бокралар, су өчен краннар сатып алу), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү);

9) физик культураны һәм спортны үстерү, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

10) җәяүлеләр тротуары ясау, тротуар өчен бордюрлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Янил авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов

ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893